**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**08 ноябрь 2024**

**№ 1**

**ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Юртау авыл җирлегенең Юртау торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Юртау авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Юртау торак пунктында гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Дорожная, Взлётная, Л.П. Пермяков урамнарының төньягыннан керү юлларны вак таш белән каплау вак таш салу, эш өчен шартнамә буенча түләү);

- Юртау торак пункты территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территориядә үләнне чаптыру, ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)

3.Әлеге карарны Юртау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Юртау авыл җирлеге башлыгы ____________________ И.Ю.Кадыров